ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы район
Ташбилге авыл җирлеге
СОВЕТЫ
Адрес:422870 ,Ташбилге авылы ,
Үзәк ур. 32
тел: (243) 72-6-46
эл.адр.Ramzil.Ahmadeev@tatar.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Алькеевский муниципальный
Совет Тяжбердинского
сельского поселения
Адрес :422870 с. Тяжбердино,
ул. Центральная 32,
тел: (243) 72-6-46,
эл.адр.Ramzil.Ahmadeev@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 19 августы 9№

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 апрелендагы 8 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре»нә (2016.14.12, редак. үзгәрешләр һәм өстәмәләр)1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru/ сайтында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Ташбилге авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Ташбилге авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Әхмәдиев

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге Советының 2021 елның 19 августындагы 9 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.**

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Ташбилге авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 апрелендә 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Ташбилге авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2016.14.12, 8№ редак.) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

35 статья 3 кисәктә зоналарда:

**ТБ (торак бина)1 перспектив торак төзелеше зонасы:**
1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 нче таблица

| Параметр төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | | Аерым торучы гаилә йорты | 2 фатирдан артык булмаган кишәрлекле блокланган йортлар |
| **Җир кишәрлекләренең чик параметрлары** | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | **1000** | **1000** |
| Урам буйлап минималь киңлек (үтү) | м | 15 | 12 |
| **Җир кишәрлекләре чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары** | | | |
| Кишәрлекләр төзелешенең максималь проценты | % | 45 | 55 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (төзелешне җайга салу сызыгы башка күрсәткеч белән | м | 3 | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| билгеләнмәгән очракта) | | | |
| Кишәрлекнең ян чигеннән корылмаларның минималь чигенеше | м | а) 1-брандмауэр дивар мәҗбүри булганда;<br>б) 3-башка очракларда | а) 0-күрше блокларга кушылган очракларда;<br>б) 3-башка очракларда |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (төзелешне җайга салу линиясенең башкасы билгеләнмәгән булса) | м | 3 | 3 |
| Корылмаларның максималь биеклеге | м | 12 | 12 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2 | 2 |

* Таблицага искәрмә:

Җир кишәрлекләренең ян һәм арткы чикләреннән түбәндәге шартларда корылмаларның чигенү таблицасында бирелгән чигенешләрдән тайпылышлар рөхсәт ителә:

-җир кишәрлекләре хуҗаларының күрсәтелгән тайпылышларга үзара ризалыгы булу;

- төп корылмалар (торак йортлар) арасындагы ераклык 6 метр яки артып китә, ә ярдәмче корылмалар (хуҗалык корылмалары, гаражлар һ.б.) арасындагы ераклык 2 метр яки артып китә.( шулай ук ярдәмче корылмаларны блоклау рөхсәт ителә);

- күрше җир кишәрлекләрендә урнашкан корылмалар арасында янгынга каршы норматив ераклык саклана.